http://president.tatar.ru/tat/legis/law/41799

# Татарстан Республикасы Хисап Палатасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2004 елның 3 июнендә кабул ителде

## 1 БҮЛЕК. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

### 1 статья. **Татарстан Республикасы Хисап палатасының статусы**

1. Татарстан Республикасы Хисап палатасы (алга таба - Хисап палатасы) даими эшләүче дәүләт финанс контроле органы булып тора. Хисап палатасы Татарстан Республикасы Конституциясе һәм әлеге Закон нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан тљзелә.

2. Хисап палатасы үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Россия Федерациясе Бюджет кодексына, әлеге Законга, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең башка законнарына таяна. Гамәлдәге законнарда билгеләнгән бурычлар кысаларында Хисап палатасы оештыру һәм функциональ мљстәкыйльлеккә ия.

3. Хисап палатасы юридик зат булып тора, аның Татарстан Республикасы Дәүләт гербы тљшерелгән һәм үз исеме язылган мљһере бар.

4. Хисап палатасының урнашкан җире – Казан шәһәре.

### 2 статья. **Хисап палатасының бурычлары**

Хисап палатасының бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы бюджетының һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш фондлары бюджетларының күләмнәр, структура һәм

максатчыл куллану буенча керем һәм чыгым статьяларының үз вакытында үтәлешен тикшереп торуны оештыру һәм гамәлгә ашыру;

чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш фондларының бюджетлары, республика максатчан программалары, Татарстан Республикасы бюджет законнарының башка норматив хокукый актлары проектларына экспертиза уздыру;

Татарстан Республикасы бюджетында һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш фондлары бюджетларында билгеләнгән күрсәткечләрдән читкә тайпылуларны анализлау һәм аларны бетерүгә, шулай ук тулаем бюджет процессын камилләштерүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр әзерләү;

вәкаләтле банкларда һәм башка финанс-кредит учреждениеләрендә Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш фондлары

акчаларының законлы рәвештә һәм үз вакытында хәрәкәтен тикшереп тору;

Татарстан Республикасы бюджетының, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш фондлары бюджетлары үтәлешенең барышы һәм уздырыла торган контроль чараларының нәтиҗәләре хакында даими тљстә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Президентына мәгълүмат бирү.

3 статья. **Контрольне гамәлгә ашыру принциплары**

Хисап палатасы Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш фондлары бюджетлары үтәлешен законлылык, объективлык, системалылык, бәйсезлек һәм хәбәрдарлык принциплары нигезендә тикшереп тора.

## 2 БҮЛЕК. ХИСАП ПАЛАТАСЫНЫҢ СОСТАВЫ ҺӘМ СТРУКТУРАСЫ

4 статья. **Хисап палатасының составы**

1. Хисап палатасы Хисап палатасы Рәисеннән, Хисап палатасы Рәисе урынбасарыннан, Хисап палатасы аудиторларыннан, Хисап палатасы аппаратыннан тора.

2. Хисап палатасында љч аудитор урыны билгеләнә.

3. Хисап палатасы аппаратының структурасын һәм штатлар распи-саниесен Хисап палатасын тоту љчен каралган акчалар кысаларында Хисап палатасы Рәисе тәкъдиме буенча Хисап палатасы Коллегиясе раслый.

5 статья. **Хисап палатасы Рәисе һәм Хисап палатасы Рәисе урынбасары**

1. Хисап палатасы Рәисе һәм Рәисе урынбасары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан биш елга билгеләп куела. Хисап палатасы Рәисе кандидатурасын Татарстан Республикасы Президенты тәкъдим итә. Хисап палатасы Рәисе урынбасары кандидатурасын Хисап палатасы Рәисе тәкъдим итә.

2. Югары белемле һәм дәүләт идарәсе, дәүләт контроле, икътисад, финанслар, хокук љлкәсендә һљнәри эшчәнлек тәҗрибәсе булган гражданнар Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары була алалар.

3. Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Прокуроры, Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе һәм Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе белән якын туганлык мљнәсәбәтләрендә торырга тиеш түгел.

4. Хисап палатасы Рәисен һәм Рәисе урынбасарын билгеләп кую турындагы карарлар Татарстан Республикасы Дәүләт Советының сайланган депутатлары саныннан күпчелек тавыш белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителәләр.

5. Хисап палатасы Рәисе:

Хисап палатасы эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм Хисап палатасы Регламенты нигезендә аның эшен оештыра;

Хисап палатасының эше турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына хисап бирә;

Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарында һәм чит илләрдә Хисап палатасы исеменнән эш йљртә.

6. Үзенә йљкләнгән вәкаләтләрне үтәү йљзеннән, Хисап палатасы Рәисе боерыклар һәм әмерләр чыгара, Хисап палатасы аппараты хезмәткәрләрен эшкә ала һәм эштән азат итә, хуҗалык һәм башка тљрле шартнамәләр тљзи.

7. Хисап палатасы Рәисе урынбасары эш урыны бурычларын Хисап палатасы Регламенты нигезендә башкара, Хисап палатасы Рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын үти, Хисап палатасы Рәисе кушуы буенча Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарында һәм чит илләрдә Хисап палатасы исеменнән эш йљртә.

8. Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, аның комитетлары, комиссияләре һәм эшче тљркемнәре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары коллегияләре утырышларында катнашырга хокуклы.

9. Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары дәүләт хакимиятенең вәкиллекле органнары, җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары депутатлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әгъзалары була алмыйлар, укыту, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән гайре, акча түләнә торган бүтән эшчәнлек белән шљгыльләнә алмыйлар.

6 статья. **Хисап палатасы аудиторлары**

1. Хисап палатасының билгеле бер юнәлештәге эшчәнлегенә җитәкчелек итүче урындагы затлар Хисап палатасы аудиторлары булып торалар. Хисап палатасы аудиторларының берәрсе җитәкчелек итә торган Хисап палатасы эшчәнлеге юнәлешенең конкрет эчтәлеген Хисап палатасы Коллегиясе билгели.

2. Хисап палатасы аудиторлары эш урыннарына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан биш елга билгеләп куелалар. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык, регламент һәм депутат этикасы комитеты аудитор урыннарына берәр кандидатура тәкъдим итәләр.

3. Хисап палатасы аудиторлары итеп югары белемле һәм дәүләт контроле, икътисад, финанслар, хокук љлкәсендә тәҗрибәсе булган гражданнар билгеләнергә мљмкин.

4. Хисап палатасы аудиторын билгеләп кую турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары Татарстан Республикасы Дәүләт Советының сайланган депутатлары саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

5. Хисап палатасында вакантлы урын барлыкка килгәндә, ул ике ай эчендә биләнергә тиеш.

6. Хисап палатасы аудиторлары, Хисап палатасы Регламенты билгеләгән үз компетенциясе чикләрендә, үзләре җитәкләгән юнәлешләрнең эшчәнлеген оештыруга

бәйле барлык мәсьәләләрне мљстәкыйль хәл итәләр һәм аның нәтиҗәләре љчен җаваплы булалар.

7. Хисап палатасы аудиторлары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, аның комитетлары һәм комиссияләре, башкарма хакимиятнең республика органнары коллегияләре һәм башка дәүләт органнары утырышларында катнашырга хокуклы.

8. Хисап палатасы аудиторлары, укыту, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән гайре, акча түләнә торган бүтән эшчәнлек белән шљгыльләнә алмыйлар.

7 статья. **Хисап палатасы Коллегиясе**

1. Хисап палатасы эшен планлаштыру һәм оештыру, контроль-ревизия эшчәнлеге методологиясе мәсьәләләрен, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрелә торган хисапларны һәм мәгълүмати хәбәрләрне карау љчен Хисап палатасы Коллегиясе тљзелә. Хисап палатасы Коллегиясе составына Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары һәм Хисап палатасы аудиторлары керә.

2. Хисап палатасы Рәисе тәкъдиме буенча Коллегия Хисап палатасының Регламентын кабул итә, Хисап палатасы аудиторлары җитәкләгән эшчәнлек юнәлешләренең эчтәлеген раслый.

3. Коллегия утырышларының кљн тәртибенә керүче мәсьәләләр буенча карарлар Коллегия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә, тавышлар тигез булганда Хисап палатасы Рәисе тавышы хәлиткеч кљчкә ия.

8 статья. **Хисап палатасы аппараты**

1. Хисап палатасы аппараты Хисап палатасы инспекторларыннан һәм штаттагы башка хезмәткәрләрдән тора.

2. Хисап палатасы инспекторларының хезмәт вазыйфаларына Хисап палатасы компетенциясе кысаларында контрольне турыдан-туры оештыру һәм уздыру керә.

3. Хисап палатасы аппараты хезмәткәрләренең хокуклары, бурыч-лары һәм җаваплылыгы, шулай ук аларның хезмәт итү шартлары әлеге Закон, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" Татарстан Республикасы Законы, хезмәт турында Россия Федерациясе законнары һәм башка норматив хокукый актлар белән билгеләнә.

## 3 БҮЛЕК. ХИСАП ПАЛАТАСЫ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ТӘРТИБЕ

9 статья. **Хисап палатасы эшчәнлегенең тљрләре**

Әлеге Законның 2 статьясында бәян ителгән бурычларны гамәлгә ашыру процессында Хисап палатасы контроль-ревизия, эксперт-аналитик, мәгълүмати һәм эшчәнлекнең башка тљрләрен гамәлгә ашыра, Татарстан Республикасы бюджетының һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш фондлары бюджетларының үтәлешенә контрольнең бердәм системасын тәэмин итә, бу түбәндәгеләрне күздә тота:

хисап елында Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасының бюджеттан тыш фондлары бюджетлары үтәлешенә оператив контроль, бюджет акчаларының нәтиҗәле файдалануына аудит оештыру һәм уздыру;

Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш фондлары бюджетларының аерым бүлекчәләре һәм статьялары буенча комплекслы ревизияләр һәм тематик тикшерүләр уздыру;

Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы законнары һәм башка тљрле норматив хокукый актлары, шартнамәләре һәм килешүләре, республика программалары, Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы финансларына кагыла торган башка документлар проектларына экспертиза ясау;

Татарстан Республикасы бюджетын үтәү хакындагы хисапка тышкы тикшерү уздыру һәм аның нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим итү;

бюджет процессында килеп чыккан кимчелекләрне анализлау һәм тикшерү, аларны бетерү, шулай ук тулаем бюджет турындагы законнарны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү;

хисап елында Татарстан Республикасы бюджетын һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш фондлары бюджетларын үтәү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советына бәяләмә эшләп тапшыру;

Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары таләпләренә бәяләмәләр һәм җаваплар әзерләү һәм җибәрү.

10 статья. **Хисап палатасының эшен оештыру һәм планлаштыру**

1. Хисап палатасы үзенең эшен, Хисап палатасы эшчәнлегенең барлык тљрләрен һәм юнәлешләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы бюджетының үтәлешенә һәрьяклап системалы контроль ясауны тәэмин итү ихтыяҗыннан чыгып формалашучы еллык һәм агымдагы планнар һәм программалар нигезендә тљзи.

2. Планлаштыру Хисап палатасы тарафыннан әлеге максатлар љчен эшләнелә торган техник-икътисадый нормалар һәм нормативлар, контроль һәм ревизия стандартлары, методик күрсәтмәләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасы Президенты йљкләгән эшләр, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы йљкләгән эшләр, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының гомуми саныннан кимендә биштән бере керткән мљрәҗәгатьләр Хисап палатасының эш планнарына һәм программаларына һичшиксез кертелергә тиеш.

3. Хисап палатасының эш планнарын һәм программаларын формалаштырганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары һәм комиссияләре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары таләпләре һичшиксез каралырга тиеш.

4. Еллык план проекты Хисап палатасы Коллегиясендә карала һәм раслана.

5. Планнан тыш контроль чаралар Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кушуы буенча, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының гомуми саныннан кимендә биштән бере мљрәҗәгать иткәндә яисә Хисап палатасы Коллегиясе карары нигезендә уздырыла.

11 статья. **Хисап палатасы Регламенты**

Хисап палатасы эшчәнлегенең эчке мәсьәләләре, Хисап палатасы Рәисе урынбасары һәм аудиторлар арасында вазыйфаларны бүлешү, Хисап палатасы аппараты структур бүлекчәләренең вазыйфалары һәм үзара хезмәттәшлек итү, эшләрне алып бару, контроль һәм башка эшчәнлеккә караган барлык тљр чараларны әзерләү һәм уздыру тәртибе аның Коллегиясе тарафыннан раслана торган Хисап палатасы Регламенты нигезендә билгеләнә.

12 статья. **Хисап палатасының контрольлек вәкаләтләре гамәлләре даирәсе**

1. Татарстан Республикасындагы барлык дәүләт органнары (шул исәптән аларның аппаратлары) һәм учреждениеләре, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш фондлары Хисап палатасының контрольлек вәкаләтләре даирәсенә керә.

2. Әгәр җирле үзидарә органнары, тљрләренә һәм оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә предприятиеләр, оешмалар, банклар, иминләштерү компанияләре һәм башка финанс-кредит учреждениеләре, аларның берлекләре, ассоциацияләре һәм башка тљрдәге берләшмәләре Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алсалар, акча күчерсәләр, акчадан файдалансалар яисә республика милкеннән файдалансалар йә аның белән идарә итсәләр, Татарстан Республикасы законнары нигезендә яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан бирелгән салым ташламаларына һәм башка тљрле ташламаларга һәм љстенлекләргә ия булсалар, Хисап палатасының контрольлек итү вәкаләтләре шулай ук аларга да кагыла.

3. Иҗтимагый берләшмәләр, дәүләтнеке булмаган фондлар һәм башка тљрле коммерция белән шљгыльләнмәүче дәүләти булмаган оешмалар эшчәнлегенә Хисап палатасының контрольлек вәкаләтләре Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алу, акча күчерү яки бюджет акчаларыннан файдалану, республика милкеннән файдалану һәм аның белән идарә итүгә бәйле љлешендә, шулай ук Татарстан Республикасы законнары нигезендә яисә Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан бирелгән дәүләт гарантияләренә, салым һәм башка ташламаларга һәм љстенлекләргә бәйле љлешендә кагылалар.

13 статья. **Хисап палатасы таләпләре буенча мәгълүмат бирү**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә банклар һәм башка тљрле финанс-кредит учреждениеләре, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, аларның урындагы затлары Хисап палатасы таләпләре буенча аның эшчәнлеген тәэмин итү љчен кирәкле мәгълүмат бирергә тиеш.

2. Ревизияләр һәм тикшерүләр уздырганда Хисап палатасы тикшерелә торган предприятиеләрдән, учреждениеләрдән, оешмалардан, банклардан һәм башка кредит-финанс учреждениеләреннән үз компетенциясенә керүче мәсьәләләр буенча барлык кирәкле документларны һәм мәгълүматларны ала.

3. Хисап палатасы таләбе буенча банклар һәм башка кредит-финанс учреждениеләре аңа операцияләр һәм тикшерелә торган объектларның счетлары торышы хакында документаль расланган тиешле мәгълүматлар бирергә бурычлы. Калган предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар Хисап палатасы таләбе буенча алар белән операцияләр һәм исәп-хисаплар буенча белешмәләр һәм документларның күчермәләрен бирергә тиеш.

4. Күрсәтелгән органнарның, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның

җаваплы затлары Хисап палатасы таләбе буенча кирәкле мәгълүматны яки документларны вакытында бирүдән баш тартса яисә тайпылса, шулай ук ялган мәгълүмат бирсә, законда билгеләнгән җаваплылыкка тартылалар.

14 статья. **Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешенә оператив контроль**

1. Хисап палатасы Татарстан Республикасы бюджетын үтәү процессында акчаның тулысынча һәм вакытында керүен, Татарстан Республикасы бюджетының закон нигезендә расланган күрсәткечләре белән чагыштырганда бюджет ассигнованиеләренең чынбарлыкта ничек тотылуын контрольдә тота, тайпылышларны һәм закон бозуларны ачыклый, аларны анализлый һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр кертә.

2. Оператив контроль мәгълүматлары ревизияләрне һәм тикшерүләрне планлаштырганда файдаланыла.

15 статья. **Ревизияләр һәм тикшерүләр**

1. Комплекслы ревизияләр һәм тематик тикшерүләр тикшерелә торган объектлар урнашкан урыннарда уздырыла. Аларны уздыру сроклары, аларның күләмнәре һәм ысуллары Хисап палатасы тарафыннан билгеләнә.

2. Җитештерү-хуҗалык эшчәнлегенең законлылыгын, бухгалтерлык исәбенең һәм финанс хисабының дљреслеген документаль раслау нигезендә тикшерелә торган объект һәм Татарстан Республикасы бюджеты арасында үзара түләүләрнең үз вакытында һәм ни дәрәҗәдә тулы кертелүе ревизияләр һәм тикшерүләр уздырганда ачыклана.

3. Ревизия яисә тикшерү йомгаклары буенча хисап тљзелә, аның дљреслеге љчен Хисап палатасының тиешле урындагы затлары шәхсән җаваплы булалар.

4. Уздырылган ревизияләр һәм тикшерүләрнең нәтиҗәләре хакында Хисап палатасы Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына хәбәр итә, мәгълүматларны башкарма хакимиятнең тиешле республика органнары, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләре игътибарына җиткерә.

5. Дәүләткә китерелгән зыян һәм ачыкланган закон бозулар хакында Хисап палатасы Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына хәбәр итә, ә җинаять җаваплылыгына китерерлек закон бозулар табылганда тиешле материалларны хокук саклау органнарына тапшыра.

6. Ревизияләр һәм тикшерүләр уздырганда Хисап палатасының урындагы затлары тикшерелә торган объектларның оператив эшчәнлегенә катнашмаска, шулай ук ревизия (тикшерү) тәмамланганчы һәм аның нәтиҗәләре акт (бәяләмә) рәвешендә рәсмиләштерелгәнче үз фикерләрен киң җәмәгатьчелеккә белдермәскә тиешләр.

7. Хисап палатасының урындагы затлары һәм аның эшенә җәлеп ителгән белгечләр ревизияләр һәм тикшерүләр барышында алынган мәгълүматларны Хисап палатасы кушкан эшләрне башкарганда гына файдалана алалар.

16 статья. **Татарстан Республикасының эчке һәм тышкы дәүләт бурычының торышын һәм кредит ресурсларын файдалануны тикшереп тору**

Хисап палатасы түбәндәгеләрне тикшереп тора:

Татарстан Республикасының эчке һәм тышкы дәүләт бурычы белән идарә итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан чит дәүләтләрдән һәм финанс оешмаларыннан алына торган чит ил кредитлары һәм заемнарының законлы, рациональ һәм нәтиҗәле файдаланылуын;

кире кайтару шарты белән бирелә торган үзәкләштерелгән финанс ресурсларының нәтиҗәле урнаштырылуын;

дәүләт кредитлары, дәүләт гарантияләре, шулай ук чит дәүләтләргә һәм халыкара оешмаларга түләүсез нигездә акча бирүне.

17 статья. **Татарстан Республикасы бюджеттан тыш фондларын тикшереп тору**

Хисап палатасы Татарстан Республикасы бюджеттан тыш фондлары акчаларының һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары карамагындагы валюта средстволарының туплануын һәм нәтиҗәле файдаланылуын тикшереп тора.

18 статья. **Татарстан Республикасы милке белән эш итүдән һәм идарә итүдән алынган акчаларның Татарстан Республикасы бюджетына керүен тикшереп тору**

Хисап палатасы түбәндәгеләрдән алынган акчаларның Татарстан Республикасы бюджетына керүен тикшереп тора:

Татарстан Республикасы милкендәге (шул исәптән аны хосусыйлаштырудан, сатудан алынган) мљлкәт белән эш итүдән;

Татарстан Республикасы милкендәге объектлар белән идарә итүдән.

19 статья. **Банк системасын тикшереп тору**

Хисап палатасы түбәндәгеләрне тикшереп тора:

Татарстан Республикасы бюджеты акчаларына хезмәт күрсәтү љлешендә банклар һәм финанс-кредит учреждениеләре эшчәнлеген;

Татарстан Республикасының дәүләт бурычына хезмәт күрсәтү буенча банклар эшчәнлеген.

20 статья. **Хисап палатасы экспертизасы һәм бәяләмәсе**

1. Хисап палатасы түбәндәгеләр буенча экспертиза уздыра һәм бәяләмә бирә:

Татарстан Республикасы бюджеты проекты, аның керем һәм чыгым статьяларының нигезләнгән булуы, Татарстан Республикасының эчке һәм тышкы дәүләт бурычының күләмнәре һәм бюджет кытлыгы;

Татарстан Республикасы бюджетының үтәлеше хакындагы хисап;

Татарстан Республикасында бюджет-финанс сәясәте һәм бюджет процессын камилләштерү проблемалары;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелә торган бюджет-финанс мәсьәләләренә караган законнарның һәм башка норматив хокукый актларның проектлары;

Татарстан Республикасы бюджеты лычен хокукый нәтиҗәләр китереп чыгарырлык Татарстан Республикасы шартнамәләре һәм килешүләре проектлары;

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана торган программаларның проектлары буенча.

2. Үз компетенциясенә керә торган башка мәсьәләләр буенча Хисап палатасы түбәндәге нигезләрдә бәяләмәләр яисә язма җаваплар әзерли һәм тапшыра:

Татарстан Республикасы Президенты күрсәтмәләре буенча;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының тиешле карарлар белән рәсмиләштерелгән күрсәтмәләре буенча;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары һәм комиссияләре таләпләре буенча;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары таләпләре буенча;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты таләпләре буенча;

җирле үзидарә органнары таләпләре буенча.

3. Таләпне карау һәм бәяләмә әзерләү яки моңардан баш тарту хакында карар Хисап палатасы Коллегиясендә кабул ителә. Баш тарткан очракта Хисап палатасы Рәисе, баш тартуның сәбәбен күрсәтеп, таләпне кире кайтара.

4. Үз карамагындагы мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасының вәкиллекле һәм башкарма хакимият органнары кабул итә торган карарларга Хисап палатасының бәяләмәләрендә сәяси бәя бирелә алмый.

21 статья. **Контроль чараларның нәтиҗәләрен анализлау**

1. Хисап палатасы уздырыла торган контроль чараларның йомгакларына системалы тљстә анализ ясый, Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен туплау һәм акчаларын тоту барышында табылган тайпылышларның һәм бозуларның сәбәпләрен һәм нәтиҗәләрен гомумиләштерә һәм тикшерә.

2. Алынган мәгълүматлар нигезендә Хисап палатасы Татарстан Республикасының бюджет законнарын камилләштерү һәм бюджет-финанс системасын үстерү буенча тәкъдимнәр эшли һәм аларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертә.

22 статья. **Хисап палатасының башка контроль органнар белән үзара хезмәттәшлеге**

1. Татарстан Республикасының дәүләт контроль органнары, ведомстволарның үз контроль

органнары, башка контроль органнар Хисап палатасы эшчәнлегенә ярдәм итәргә, уздырыла торган ревизияләр һәм тикшерүләрнең нәтиҗәләре хакында аның таләбе буенча мәгълүмат бирергә тиешләр.

2. Контроль-ревизия эшчәнлеген гамәлгә ашырганда Хисап палатасы законнар нигезендә үзе уздыра торган чараларда катнашу ьчен үз компетенциясе чикләрендә – Татарстан Республикасының дәүләт контроль органнарын һәм аларның вәкилләрен, шулай ук шартнамәчел нигездәге дәүләтнеке булмаган аудиторлык хезмәтләрен, аерым белгечләрне җәлеп итәргә хокуклы.

3. Федераль закон нигезендә Хисап палатасы Россия Федерациясе Хисап палатасы уздыра торган контроль-ревизия чараларында катнаша ала.

23 статья. **Хисап палатасының тәкъдимнәре**

1. Уздырылган контроль чараларының нәтиҗәләре буенча Хисап палатасы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, тикшерелә торган предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар җитәкчеләренә табылган бозуларны бетерү, дәүләткә китерелгән зыянны каплау, законнарны бозуда һәм хуҗасызлыкта гаепле урындагы затларны җавапка тарту буенча чаралар күрү ьчен тәкъдимнәр җибәрә.

2. Хисап палатасының тәкъдимнәре әлеге документта күрсәтелгән вакытта, әгәр вакыты күрсәтелмәгән булса, аны алган кьннән соң 20 кьн эчендә каралырга тиеш. Тәкъдимнәр нигезендә кабул ителгән карар турында һәм аны гамәлгә ашыру чаралары хакында Хисап палатасына кичекмәстән хәбәр ителә.

3. Тикшерү яисә ревизияләр уздырганда дәүләт акчаларын һәм матди чараларны урлау һәм шулай ук хезмәт урыныннан явыз ният белән башкача файдалану очраклары ачыкланса, Хисап палатасы тикшерү яисә ревизия материалларын хокук саклау органнарына җибәрә.

24 статья. **Хисап палатасы күрсәтмәсе**

1. Тикшерелә торган объектларның хуҗалык, финанс, коммерция һәм башка тьрле эшчәнлегендә дәүләткә турыдан-туры зыян китерүче һәм шуңа бәйле рәвештә аларга кичекмәстән чик кую таләп ителерлек закон бозулар табылганда, шулай ук Хисап палатасының тәкъдимнәрен карау срокларын һәм тәртибен белә торып яисә системалы тьстә бозганда, контроль чаралар уздыруга комачаулык иткән очракта Хисап палатасы тикшерелә торган предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар администрацияләренә мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирергә хокуклы.

2. Хисап палатасы күрсәтмәләренә Хисап палатасы Рәисе яисә Хисап палатасы Рәисе урынбасары имза сала.

3. Башкарма хакимиятнең республика органнары җитәкчеләренә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әгъзаларына Хисап палатасы җибәрә торган күрсәтмәләр Хисап палатасы Коллегиясе тарафыннан кабул ителә, аңа Хисап палатасы Рәисе яисә Хисап палатасы Рәисе урынбасары имза сала.

4. Хисап палатасы күрсәтмәләрен берничә мәртәбә яисә тиешенчә үтәмәгәндә, Хисап палатасы Коллегиясе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы белән килешеп, тикшерелә торган предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмаларның исәп-хисап счетлары буенча

барлык тљр финанс түләүләрен һәм исәп-хисап операцияләрен туктатып тору хакында карар кабул итә ала.

5. Күрсәтмәне Хисап палатасы Коллегиясе гамәлдән чыгара яисә аңа үзгәрешләр кертә ала.

6. Судка күрсәтмәгә карата шикаять бирелергә мљмкин.

25 статья. **Хисап палатасы Коллегиясе әгъзаларының аерым фикере**

1. Тикшерүләр һәм ревизияләр нәтиҗәләре турындагы хисаплар Хисап палатасы Коллегиясе каравына шуларны уздыру љчен җаваплы аудиторлар тарафыннан тапшырыла. Хисап палатасы Коллегиясе аларны карау йомгаклары буенча карар кабул итә,530карарга Хисап палатасы Коллегиясе утырышында рәислек итүче имза сала.

2. Хисап палатасы Коллегиясенең коллегия карары белән риза булмаган әгъзасы яисә бер тљркем әгъзалары љч кљн эчендә Хисап палатасы Рәисенә аерым фикерен җиткерергә хокуклы, ул Хисап палатасы Коллегиясе карарына теркәлә һәм аның белән бергә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Тикшерүләр һәм ревизияләр материалларын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәргәндә Хисап палатасы Коллегиясе әгъзаларының аерым фикере мәҗбүри тәртиптә рәсмиләштерелә.

26 статья. **Тикшерүләр һәм ревизияләр уздырганда Хисап палатасы инспекторларының вәкаләтләре**

1. Хисап палатасы испекторлары бюджет-финанс контроле үткәрү буенча үзләренең хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасының дәүләт органнарына, оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә предприятиеләргә, учреждениеләргә һәм оешмаларга, банкларга һәм башка кредит-финанс учреждениеләренә, законда башкасы каралмаганда, теләсә кайсы производство, склад, сәүдә һәм канцелярия биналарына тоткарлыксыз керергә.

2. Тикшерелә торган объектларның җитәкчеләре тикшерү яисә ревизия уздыра торган Хисап палатасы инспекторларына нормаль эш шартлары тудырырга, аларга кирәкле биналар, транспорт һәм элемтә чаралары бирергә, инспекторларга техник хезмәт күрсәтүне һәм эш кәгазьләре белән бәйле гамәлләрне үтәүне тәэмин итәргә тиешләр.

27 статья. **Хисап палатасы инспекторлары таләпләрен үтәүнең мәҗбүрилеге**

Хисап палатасы инспекторларының үз хезмәт бурычларын башкару белән бәйле таләпләрен үтәү Татарстан Республикасы дәүләт органнары, шулай ук, кемгә буйсынуларына һәм оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар љчен мәҗбүри.

Хисап палатасы урындагы затларының законлы таләпләрен үтәмәү, шулай ук аларга йљкләнгән бурычларны үтәүгә комачауларлык гамәлләр законда билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка китерә.

28 статья. **Хисап палатасы инспекторларының җаваплылыгы**

Хисап палатасы инспекторлары уздырыла торган тикшерүләр һәм ревизияләр нәтиҗәләре буенча дәүләт органнарына җибәрелә яисә халыкка җиткерелә торган материалларның дљреслеге љчен, шулай ук дәүләт серен яки закон нигезендә саклanучы серне ачкан љчен законнар нигезендә җаваплы булалар.

## 4 БҮЛЕК. ЙОМГАКЛАУ НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕ

29 статья. **Хисап палатасы хезмәткәрләренең хокукый статусы гарантияләре**

1. Хезмәт вазыйфаларын башкаруга комачаулау яки кемнеңдер файдасын күздә тоткан карар чыгарту максаты белән Хисап палатасының урындагы затларына йогынты ясау, кљч куллану, мәсхәрәләү һәм шулай ук яла ягу яисә аларның хезмәт вазыйфаларын үтәүләре хакында ялган хәбәр тарату Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән җаваплылыкка тартуга китерә.

2. Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары һәм Хисап палатасы аудиторлары һљнәри бәйсезлек гарантияләренә ия затлар. Алар фәкать түбәндәге очракларда гына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары нигезендә вазыйфаларыннан вакытыннан алда азат ителергә мљмкин:

а) законнарны бозганда яисә хезмәт урыныннан явыз нияттә файдаланганда, әгәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының сайланган депутатлары саныннан күпчелеге мондый карарны яклап тавыш бирсә;

б) отставкага китүе хакында шәхси гариза биргәндә;

в) закон кљченә кергән суд карары нигезендә алар хокукка сәләтсез дип танылганда;

г) аларга 65 яшь тулганда;

д) яңа чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советын формалаштырганда, бу чакта Хисап палатасы Рәисенең, Хисап палатасы Рәисе урынбасарының, Хисап палатасы аудиторларының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының сайланган депутатлары саныннан күпчелеге мондый карарны яклап тавыш бирсә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшли башлауга алты ай узганнан соң яңа чакырылыш тарафыннан кабул ителергә мљмкин.

Әлеге пунктның "а" пунктчасында каралган нигезләр буенча Хисап палатасы Рәисен, Хисап палатасы Рәисе урынбасарын, Хисап палатасы аудиторларын вакытыннан алда азат итү турындагы тәкъдим Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Президенты яисә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән саныннан љчтән береннән дә ким булмаган сандагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тљркеме тарафыннан кертелә.

3. Хисап палатасының эшчәнлеге Татарстан Республикасы Дәүләт Советын таратуга бәйле рәвештә туктатыла алмый.

30 статья. **Хисап палатасы эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итү**

Хисап палатасы эшчәнлеген тәэмин итү аңа йљкләнгән бурычларны һәм вәкаләтләрне

үтәү өчен кирәк булган дәрәҗәдә күздә тотыла.

Хисап палатасын тотуга кирәкле акчалар Татарстан Республикасы бюджетына аерым юл итеп кертелә.

Финанс елы дәвамында Хисап палатасын тотуга бюджет ассигнованиеләре күләмен Татарстан Республикасы бюджеты турындагы закон белән билгеләнгәннән киметүгә юл куелмый.

31 статья. **Хисап палатасы хезмәткәрләрен матди һәм социаль тәэмин итү**

1. Дәүләт Хисап палатасы хезмәткәрләрен матди һәм социаль тәэмин итү буенча тиешле чаралар күрә.

2. Хисап палатасы аппараты хезмәткәрләре окладлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты хезмәткәрләренең окладлары дәрәҗәсендә билгеләнә. Хисап палатасы аппараты хезмәткәрләренең окладларына өстәмәләр Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә һәм күләмнәрдә билгеләнә.

3. Хисап палатасы Рәисенә айлык оклад һәм өстәмәләр Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары хезмәт хакы һәм шул окладка өстәмәләр күләмендә билгеләнә.

4. Хисап палатасы Рәисе урынбасарына айлык оклад һәм аңа өстәмәләр Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарының окладьі һәм шул окладка өстәмәләр күләмендә билгеләнә.

5. Хисап палатасы аудиторына айлык оклад һәм аңа өстәмәләр Татарстан Республикасы министрының окладьі һәм аңа өстәмәләр күләмендә билгеләнә.

6. Хисап палатасы хезмәткәрләренә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты хезмәткәрләре өчен билгеләнгән медицина, көнкүреш һәм транспорт хезмәте күрсәтү тәртибе кагыла.

7. Хисап палатасы Рәисенә, Хисап палатасы Рәисе урынбасарына һәм Хисап палатасы аудиторларына һәм аларның гаиләләренә медицина һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү, аларның иминлеген тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының урындагы тиешле затларына хезмәт күрсәтү дәрәҗәсендә билгеләнә.

32 статья. **Тышкы элемтәләр**

Хисап палатасы Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының, чит дәүләтләрнең хисап һәм контроль палаталары һәм парламент контроле органнары, халыкара берләшмәләр белән элемтә тота, алар белән хезмәттәшлек итү турында килешүләр төзи.

33 статья. **Хисап палатасы эшчәнлеге турында хисаплылык һәм мәгълүмат**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Хисап палатасының эше турында еллык хисапны карый, ул һичшиксез басылып чыгарга тиеш. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына Хисап палатасы эшчәнлегенең аерым мәсьәләләре буенча хисаплары

кертелергә мљмкин.

2. Хисап палатасы Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм массакүләм мәгълүмат чараларына үз эшчәнлеге турында даими рәвештә мәгълүмат бирә.

3. Дәүләт серен саклау белән бәйле тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча материаллар Татарстан Республикасы Дәүләт Советына ябык утырышларда карау љчен тәкъдим ителә.

34 статья. **Әлеге Законның үз кљченә керүе**

Әлеге Закон рәсми тљстә басылып чыккан кљненнән үз кљченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан, Кремль

2004 елның 7 июне

N 37-ЗРТ